ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 116 от «20» 08 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча Комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 29 нчы сентябрендәге «2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Комиссиясен төзү турында» 1185 санлы карары нигезендә, Мамадыш муниципаль районы территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен координацияләү һәм тәэмин итү максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Комиссия төзергә (килешү буенча).

2. Әлеге карарга теркәлеп килүче «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү комиссиясе турында» Нигезләмәне, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү Комиссиясе составын расларга. (1, 2 нче санлы кушымталар).

3. Мамадыш шәһәре һәм Мамадыш муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1 2019 елның 1 сентябренә кадәр, билгеләнгән тәртиптә, Дәүләт статистикасы органнарына шәһәр һәм авыл торак пунктларында торак һәм торак булмаган фонд йортлары буенча, төзелеш төре (торак яки торак булмаган) һәм балансында төзелеш булган оешма, предприятие атамасын, адреслар исемлеген әктуальләштерү һәм оештыру планнарын төзү өчен торак урыннары саны һәм яшәү яисә тору урыны буенча торак урыннарында яшәүче һәм теркәлгән затлар саны турында мәгълүматлар күрсәтеп, белешмәләр бирергә.

3.2 2019 елның 1 сентябренә кадәр муниципаль берәмлекләрдә йорт саннары һәм фатир номерлары язылган күрсәткечләрнең булуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә эшләүче массакүләм мәгълүмат чараларына Дәүләт

статистикасы органнары белгечләренә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның максатларын, бурычларын һәм әһәмиятен яктыртуга юнәлдерелгән мәгълүмати-аңлату эшләре алып баруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. «Мамадыш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә мәшгульлек үзәгендә теркәлгән эшсез һәм мәшгульсез гражданнарны 2020 елда Бөтенроссия халык санын алуга җәлеп итүдә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мамадыш муниципаль районы
Башлыгы А.П. Иванов

Мамадыш муниицпаль
районы Башлыгының _____
20.08., 2019 ел, 116 санлы
карарына 1 нче санлы Кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү комиссиясе турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү Комиссиясе (алга таба-Комиссия) җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен координацияләү һәм аларның үзара ярашуын тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләрен оператив хәл итү максатларында оештырылган.

2. Комиссия үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, «Бөтенроссия халык санын алу турында» 2002 елның 25 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Президенты Указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү комиссиясе турындагы нигезләмә, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә алып бара.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү, үткәрү буенча җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү.

4. Үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру максатларында Комиссия:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү барышын контрольдә тота;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуга әзерлек һәм аның оператив нәтиҗәләре белән бәйле мәсьәләләрне карый;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрүне оештыру планын раслый;

Түбәндәге мәсьәләләр буенча булган тәкъдимнәрне карый:

2020 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү эшенә төрле оештыру-хокукый формадагы оешмаларны җәлеп итү;

тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче гражданнарны халык турында мәгълүмат җыюга, шулай ук халык турында белешмәләрне эшкәртүгә җәлеп итүне оештыру турында;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру:

халык турында мәгълүмат җыюга җәлеп ителүче затларны укыту һәм эшләү өчен яраклы җиһазлар һәм элемтә чаралары белән җиһазландырылган саклanучы биналар белән тәэмин итү;

исәпкә алу кәгазьләрен һәм 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның башка документларын саклау максатында саклана торган биналар белән тәэмин итү;

2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру вакытында транспорт һәм элемтә чаралары белән тәэмин итү;

2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру эшләрен оештыру өчен аларның ресурсларыннан һәм биналарыннан файдалану максатында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрен җәлеп итү, шул исәптән халык санын алуда катнашу өчен дәүләт хезмәтләренең бердәм порталына керү мөмкинлеген бирү;

халык турында мәгълүмат җыючы затларның иминлеген, исәпкә алу кәгазьләренең һәм 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның башка документларының сакланышын тәэмин итүне оештыру;

торак комплексларының ябык территорияләренә, гражданнарның коммерцияле булмаган берләшмәләренә һ. б. керүне тәэмин итүне оештыру;

2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуга кагылышлы басма агитация материаллары урнаштыру максатында махсус җиһазландырылган урыннар бүлеп бирү;

җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен Интернет челтәрендә дәүләт хезмәтләренең бердәм порталында Халык санын алуда катнашуга җәлеп итү;

билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан шәһәр һәм авыл торак пунктларында торак һәм торак булмаган фонд йортлары буенча, төзелеш төре (торак яки торак булмаган йорт) һәм төзелеш балансында булган оешма, предприятие атамасын күрсәтеп белешмәләр бирү; адреслар исемлеген актуальләштерү һәм оештыру планнарын төзү өчен торак урыннары саны һәм яшәү урыны буенча торак урыннарында яшәүче һәм теркәлгән затлар саны турында мәгълүматлар бирү;

«Бөтенроссия халык санын алу турында» 2002 елның 25 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 пункты нигезендә торак, торак-эксплуатация оешмалары, идарәче оешмалар һәм компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак-төзелеш кооперативлары белән идарә итү органнары тарафыннан яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлгән затлар турында административ белешмәләр бирү; дәүләт, муниципаль һәм шәхси торак фондындагы торак урыннары буенча (фатир саен

аерым карточкалар, йорт (фатир саен) китаплары) халыкны теркәү исәбен алып бара торган җирле үзидарә органнары тарафыннан административ белешмәләр бирү;

2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүдә һәм үткәрүдә актив катнашкан физик һәм юридик затларны бүләкләү.

5. Комиссия хокуклы:

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләренең 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү барышы турында мәгълүматын тыңларга;

Комиссия эшенә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен, фәнни, иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итәргә;

комиссиягә йөкләнгән бурычларны хәл итү белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү өчен эш төркемнәре төзергә.

6. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан һәм сәркатиптән тора.

Комиссия рәисе комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, комиссия утырышларының еллык планнарын раслый һәм комиссия составын яңарту турында тәкъдимнәр кертә, аның утырышын алып бара.

Комиссия рәисе булмаган вакытта яки аның кушуы буенча рәис вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия утырышлары, кирәк булган саен, әмма ярты елга кимендә, бер тапкыр, 2020 елда - еллык эш планнарына туры китереп, 3 тапкыр үткәрелә.

Комиссия утырышлары аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашкан очракта хокуклы санала. Комиссия әгъзалары аның утырышларында алыштыру хокукыннан башка катнаша.

Комиссия әгъзалары һәм чакырылган кешеләр докладлар һәм өстәмә докладлар белән чыгыш ясый, фикер алышуларда тәкъдимнәр кертә, тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы буенча белешмә бирә алалар.

Комиссия утырышларын аудио - һәм видеоконференция режимында да үткәрергә мөмкин.

8. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карарлары Комиссия рәисе яисә комиссияне алып барган аның урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы карары таләп итүче мәсьәләләр буенча Комиссия билгеләнгән тәртиптә тиешле тәкъдимнәр кертә.

9. Комиссиянең компетенциясе кысаларында кабул ителгән карарлары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль

берәмлекләрендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүгә һәм үткәрүгә ярдәм итү максатларында төзелгән комиссияләр, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары өчен мәҗбүри булып тора.

10. Комиссия эшчәнлеген туктату турындагы карар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы тарафыннан кабул ителә.

11. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында Дәүләт статистикасы органнары белгечләре тарафыннан башкарыла.

Мамадыш муниицпаль
районы Башлыгының _____
20.08., 2019 ел, 116 санлы
карарына 2 нче санлы Кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Иванов Анатолий Петрович | Мамадыш муниципаль районы башлыгы- комиссия рәисе |
| Дәрҗеманов Илшат Миннеәсхәт улы | муниципаль районның Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| Хәбибуллина Фазилә Гаяз кызы | Алабуга шәһәре Дәүләт статистика бүлеге әйдәп баручы белгеч-эксперты,(Мамадыш шәһәре), комиссия рәисе урынбасары |
| Шәмсетдинова Роза Рәфкать кызы | Бөтенроссия халык санын алу - 2020 үткәрү буенча вәкаләтле вәкил , комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Самигуллин Ришат Роберт улы | Мамадыш муниципаль районы башлыгы урынбасары |
| Хуҗаҗанов Муса Рөстәм улы | муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Гарипов Рәшит Мөхәммәтдин улы | Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Усачев Леонид Борисович | Россия Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлеге начальнигы |
| Миннеханов Рамил Минһаҗ улы | муниципаль район башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече |

| | |
|---|---|
| Нәфиков Таһир Габдулла улы | муниципаль район башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Сергеев Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы финанс-бюджет палатасы җитәкчесе |
| Һадиуллин Ленар Хәлим улы | «Мамадыш муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре Палатасы» ДКУ директоры |
| Хөснетдинова Ләйлә Рафис кызы | «Мамадыш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры |
| Мотыйгуллина Зөһрә Зиннур кызы | Яр Чаллы шәһәренең ТР БТИ АҖ Мамадыш филиалы бүлекчәсе җитәкчесе |
| Ханова Светлана Наил кызы | «Татмедиа» АҖ филиалы җитәкчесе – баш мөхәррире |
| Муллахмәтова Гөлнара Гафур кызы | Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсенең Мамадыш бүлеге начальнигы вазыйфаларын башкаручы |
| Әхмәтшина Айгөл Мәсхүт кызы | муниципаль район башкарма комитетының ГХАТ бүлеге җитәкчесе |
| Мөбарәкшина Гөлүсә Раиф кызы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча миграция мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе |